**/Укучылар иҗаты/**




## *Тукай туган көн – Туган тел көне*

26нчы апрель көнне Габдулла Тукайның туууына 139 ел тула.Тукай – татар шигъриятенең иң якты йолдызы, милләтебезнең йөзек кашы. Шагыйрь калдырган иҗат мирасы — безнең горурлыгыбыз. Татар халкы Тукае булу белән бәхетле. Габдулла Тукай туган көн – Туган тел көне ул. Ел саен бу көн мәктәптә олы бәйрәм төсен ала.

Бу айда бәйрәм уңаенннан төрле чаралар булып узды. Укучылар белән тагын бер кат шагыйребезнең ачы тормыш юлын күз алдыннан үткәрдек. Иҗатына һәм тормышына кагылган викторина сорауларына җавап эзләдек. Балалар бик теләп Габдулла Тукай шигырьләрен сөйләделәр, милли һәм рухи байлыкларын арттырдылар. Тукай – халкыбызның күңел көзгесе. Ул безгә үзенең шигырьләре, рухи байлыгы, милләтебезгә булган мәхәббәте белән мәңгелек мирас калдырды.

Татар телен саклыйк, аны хөрмәт итик, балаларыбызга тапшырыйк!Тукайча уйлап, татарча яшәү – ул безнең юлыбыз! Бүген ятлаган шигырьләре сезнең күңелдә саклансын иде.

*Ләйсән Закирлова, VII сыйныф укучысы*

**/Безнең уңышлар/**




20 нче апрельдә Яңа Чишмә районының мәдәният йортында **"Без бергә-2025 "** иҗади фестивальнең зональ туры булып узды. Анда якын-тирә районнардан талантлы балалар җыелып үзләренең иҗади сәләтләрен күрсәттеләр. Хайруллина Рузилә апалары җитәкчелегендәге**"Майна егетләре"** дуэтына (**Инсаф Закиров** белән **Артур Донсков**) да әлеге чарада катнашырга насыйп булды.Алар II дәрәҗә диплом белән бүләкләнделәр.



Февраль аенда республикакүләм **"Парламент дәресе-2025"** кысаларында үткәрелгән "Мәңгелек дан, онытылмас хәтер бар" дип аталган эсселәр конкурсында укучыбыз **Гафиятуллин Самат** республикада I урынны яулады. Самат Бөек Ватан сугышында катнашкан туганының сугыш юлын, батырлыкларын рәсми документларга нигезләнеп тасвирлаган иде. Нәтиҗәләр буенча, 22нче апрельдә республикабызның Дәүләт Советы бинасына тантаналы котлауга чакырылды. Укучыбыз төрле депутатлар белән очрашып, законнар кабул итү залын, төрле рәсми видеоконференцияләр үткәрелә торган залларны, Республика җитәкчеләренә багышланган музейны күреп кайтты.

*Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныфлар укытучысы*

**/Безнең спорт/**



19 нчы апрельдә Норлат районының Урта Камышлы авылында тренерлар Ф.Т.Мухаметов һәм З.З.Яруллиннар истәлегенә багышланган ачык көрәш турниры булды. Безнең VI сыйныф укучысы **Замалетдинов Зөлфәт**тә бу бәйгедә катнашып, 3 нче урынны алуга иреште.

**/Көндәлек тәнәфес/**

## *Тукай туган көнгә 10 сорау*

1) Тукайның балалар өчен язылган иң мәшһүр әсәрләренең берсе. 2) Тукайның псевдонимы. 3) Тукайның туган авылы.

4) Тукайның халык авыз иҗатыннан файдаланып язылган әкияте. 5) Тукайның татар халкына багышланган шигыре .

6) Тукайның беренче китабы. 7) Тукайның этисенең исеме.

8) Тукайның әнисенең исеме.

9) Тукайның якын дустының исеме.

10) Тукайның үлеменә китергән авыру.

*(Со рауларга җавап белән кроссворд төзергә)*

**Газетаны гамәлгә куючы** – Түбән Майна урта мәктәбе
**Мөхәррир** – Фәнүзә Гафиятуллина
**Редколлегия әгъзалары:** Зәйнәп Нурматова, Самат Гафиятуллин, Кәүсәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Мәдинә Әхсәнова, Камил Төхвәтуллин




# Мәктәп хәбәрчесе

**№4** (№65) апрель 2025 ел

*Түбән Майна урта мәктәбе газите*

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru


**/Мөхәррир минбәре/**




## *Дәрескә соңга калмыйк!*

Газетабызның һәр санында диярлек укучылар өчен кагыйдәләрне, аларның хокуклары һәм бурычлары турында даими язып киләбез. Шулай ук, кеше арасында, җәмгыятьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен һәрчак искә төшереп торабыз. Тик быелгы уку елында укучылар арасында дәрескә соңга калу очраклары ешайды. Бу проблема баланың көндәлек режимы бозылуының турыдан-туры күренеше. Режим саклауның тәрбияви әһәмияте бик зур. Чөнки ул баланы җыйнаклыкка, тәртипкә, вакытның кадерен белергә өйрәтә. Әгәр ул вакытында эшләрен эшләргә, йокларга һәм торырга өйрәнсә, дәрескә соңга калу проблемалары күзәтелмәс иде. Бүген дәрескә соңга калуга гадәтләнү – иртәгә эшкә соңга калу ул. Халык әйтмешли, чир китсә дә, гадәт кала бит.

Соңга калуның сәбәбе нигездә ике төрле булырга мөмкин. Беренчедән, бу үзеңне оештыра алмау белән бәйле. Ягъни, кеше бик иртә торса да, әйләнеп-тулганып йөреп, я телефонда утырып, мәктәпкә соңарырга мөмкин. Икенче сәбәп — йокыдан уяна алмау. Бала кирәкмәгән мавыгулар белән, ә бүгенге көндә күпчелек очракта телефонда уйнап вакыт исәбен оныта. Шуңа да иртән тора алмый, үзен таркау тоту сәбәпле, торгач та уяна алмый интегә. Барысын да соңгы мизгелдә эшләү гадәте дә вакытның кадерен белмәүнең бер чагылышы.

Әлбәттә, балаларның пунктуаль булмавының сәбәпләре күп, аларның кайберләре табигатьтән дә бирелә ала. Балада шулай ук игътибар бозылу синдромы булырга мөмкин. Ул акрынлык, тиз уйлый алмау белән характерлана. Бу очракта аны ашыктырмаска, ә ярдәм сорап неврологка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Югарыда санап кителгән сәбәпләрне читләтеп, балабыз көндәлек режимны төгәл үтәргә өйрәнсә, дәрескә соңга калулар, укудагы уңышсызлыклар булмас иде. Укучының соңга калуы үзенә генә түгел, сыйныфташларына да комачаулый. Өй эшләре тикшерелә, дәрес темасы аңлатыла башлый. Соңга калучы, шулай итеп, дәрес темасын да аңламый кала. Соңга калгач иртәнге ашы да ашамаган килеш килә дәрескә. Мондый вакытта аның башында уку түгел, әлбәттә, ашау турында гына уйлау була. Ә бу, үз чиратында, баланың укуына турыдан-туры тискәре йогынты ясый. Укытучыга да дәресне яңадан оештырырга кирәгә, вакыт әрәмгә исраф ителә.Чөнки дәрес вакыты, темага бирелгән сәгатьләр саны чикле, алар билгеле бер тәртипкә салынган. Артыгын биреп тә, темаларны өйрәнмичә калдырып та булмый. Шуңа күрә дәрескә соңга калу кечкенә генә проблема түгел. Дәресен аңламый калса, иптәшләренә комачауласа, иртәгә үзенә зыяны күбрәк тиячәк.

Әйдәгез, хөрмәтле укучылар, әти-әниләр, көн режимын сакларга бергәләп өйрәник. Йокларга яту һәм бер үк вакытта уяну гадәте сәламәтлеккә дә файдалы икәнен онытмыйк.

Яңа көнгә әзерләнегез. Кичтән мәктәпкә яисә бакчага кирәкле бар нәрсәне бергә җыегыз.Иртәгесе уку көненә кирәкле уку әсбапларын сумкагызга кичтән үк тутырып куегыз. Өй эшләре һәм башка биремнәр башкарылганмы, форма үтүкләнгәнме икәнен тикшерегез. Шушындый кечкенә генә эшләрне вакытында төгәл итеп башкарырга өйрәнсәк, киләчәгебез уңышлы булыр. Вакытын дөрес оештыра белгән кеше тормышта уңышка да ирешә. Вакыт бик кадерле икәнен барыбыз да яхшы беләбез, ул Аллаһы Тәгаләнең иң зур нигъмәтләреннән берсе. Вакыт дөнья малыннан да кыйммәтлерәк, чөнки аны берничек тә кире кайтарып булмый.

*Фәнүзә Гафиятуллина, баш мөхәррир*

**/Котлыйбыз!/**



Апрель аенда туган көннәрен билгеләп үтүче иптәшләребез V сыйныфтан **Хафизов Ирекне** (19.04), VIII сыйныфтан **Залиева Василәне** (12.04) чын күңелдән котлыйбыз. Дусларыбызга сәламәтлек, укуларында уңышлар телибез!

Шушы айда гомер бәйрәмен билгеләп үтүче укытучыларыбыз**Туктамышев Рифкать абыйны** (10.04), **Сафиуллин Илдар** абыйны (16.04) һәм **Кадыйрова Гөлнур апаны** (19.04)туган көннәре белән котлап, ныклы сәламәтлек, мактаулы эшләрендә зур уңышлар, барлык уй-хыялларыгызның тормышка ашуын телибез!



**/Мәктәп тормышы/**

## Апрель аендагы экологик чаралар

Яз житү белән, табигатьне кайгыртуга кагылышлы эшләр, экологик эчтәлекле чаралар ешая. Безнең мәктәптә дә апрель ае шундый чараларга бай булды.

1906нчы елның 1нче апрелендә ***кошларны саклау*** буенча Халыкара конвенциягә кул куела, ә безнең ил моңа 1927нче елда кушыла. Шулай итеп, бездә 1927 нче елдан башлап, кошлар көнен үткәрү гадәткә керә. Әлеге көн уңаеннан, башлангыч сыйныф укучылары арасында **"Безнең кошкайларыбыз"** исемле дәрес үткәрелде. Балалар белән кошлар иленә мавыктыргыч сәяхәт ясалды. Безнең якларда кышлаучы һәм күчеп җылы якка китүче кошлар турында мәгълүмат бирелде, кызыклы сорауларга җаваплар табылды. Күңелле уеннар бәйрәмне җанландырып җибәрде. Кошларга багышланган әлеге бәйрәм балалар өчен бик файдалы да, кызыклы да булды. Экологияне саклауда кошларның зур эш башкаруларын, аларның үзләренең дә табигатьнең бер өлеше икәнен онытмасак, аларны саклаcак иде.



20нче апрель көнне авылыбыз зиратында өмә уздырылды. Бу эштә мәктәптә укучы малайлар да катнашты. Өмә барышында зират өсте чыбыклардан чистартылды. Укучылар Туктамышев Рифкать абый җитәкчелегендә койма буйлар миләш үсентеләре утырттылар. Узган көзне зираттагы зур агачлар киселгәч, авылның ул ягы бик шыр калган иде. Шуңа күрә директор Насыйров Рафик абый зират тирәсенә артык зур үсми торган, ләкин авылга ямь биреп торырлык миләш агачлары утыртырга тәкъдим итте. Миләш үсентеләрен мәктәбебезнең күптәнге дусты – Биләр урманчылыгы җитәкчесе Нуруллин Рамил абый бүләк итеп бирде.



22 апрель – **Җир көне**. Бу көн түбәндәге максатлардан чыгып билгеләп үтелә:

- планетабызның экологик торышын кайгырту;
- табигатьнең гүзәллеген, байлыгын күрә белергә өйрәтү;
- җирнең барлык тереклек ияләре өчен уртак йорт булдыруга басым ясау;
- табигатькә сакчыл караш, кешелеклелек, киң күңеллелек сыйфатлары тәрбияләү.

Бу көнне башлангыч сыйныф укучылары үзләренең уй-фикерләрен рәсемнәр аша күрсәттеләр.

"Эколяталар көне"— Бөтенроссия табигатьне саклау социаль-мәгариф проектлары программасына кертелгән зур вакыйга. Әлеге көн ел саен 25нче апрельдә илебезнең барлык почмакларында да билгеләп үтелә. Безнең мәктәптә дә башлангыч сыйныф укучылары арасында шушы көнгә карата чара үткәрелде. Чара барышында балалар гаҗәеп әкияти геройлар — «Эколятлар» белән таныштылар. Балалар табигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен искә төшереп уздылар, табигатькә кагылышлы табышмакларны чиштеләр, рәсемнәр ясадылар. Төрле сынаулар узып, "Табигатьнең саклаучылары, яклаучылары булабыз. Беркайчан да аңа зыян кылмыйбыз"– дип ант биреп, Эколяталар сафларына керделәр. Чара ахырында мәктәп бакчасына күпьеллык чәчәкләр утыртуда катнаштылар.

***Хәбәрләрне редколлегия әгъзалары туплады***



## Апрель аендагы тәрбияви чаралар



2нче апрель "***Бөтендөнья балалар китабы көне***" буларак билгеләнеп үтелә. Шул уңайдан башлангыч сыйныф укучылары мәктәбебез китапханәсенә юл тоттылар. Китапханәче Рузалия апалары яңа китаплар белән таныштырды. Тәрбия буенча киңәшче Гөлфия апалары төрле уеннар уйнатты. Укучылар яраткан әкиятләрне һәм әдәби геройларны искә алдылар.



Яшь буынның ***ришвәтчелекнең*** нәрсә һәм аңа каршы ничек көрәшергә кирәклеген аңлату өчен мәктәптә даими чаралар үткәрелеп тора. Шунысы куандыра, укучылар бу мәсьәләдә өлкәннәр кебек үк хәбәрдар. Алар санаулы минутларда, кайчакта уйлап та тормыйча да, ришвәтчелек хакында фикер алыштылар. Төрле сүзләрдән мәкальләр төзеделәр, үз фикерләрен рәсем аша да күрсәттеләр.

4нче апрельдә сәламәтлек көне уңаеннан башлангыч сыйныф укучылары өчен "***Ишегалды уеннары***" дип аталган чара уздырылды. Телефоннарны читкә куеп саф һавада төрле уеннар уйнадылар. ***(Дәвамы өченче биттә)***



***(Башы икенче биттә)***

12 апрель –***космонавтика көне***. Атна дәвамында шушы көнгә багышланган чаралар булып узды. Мәктәп укучылары, аеруча башлангыч сыйныфлар актив катнашты. Укучылар рәсем, кул эшләре, презентация ясап чыгыш ясадылар.

Бу айда Җиңү бәйрәме якынлашу уңаеннан мәктәптә төрле чаралар уздырыла башлады. Әти-әниләр белән берлектә **"Бөек Җиңүнең 80 еллыгы уңаеннан укучылар белән нәрсәләр турында сөйләшергә"** дигән темага гомуми мәктәп җыелышы үтте. Җыелышта әти-әниләргә укучылар белән эзләнү эшләрен нинди чыганаклардан табарга мөмкинлеге турында белешмә җиткерелде.

Шулай ук, мәктәптә "Пушкин картасы" буенча Җиңүнең 80 еллыгына багышланган **квест-уен** уздырылды. Аны мәдәният йорты хезмәткәрләре әзерләп килделәр. Укучылар уенда бик теләп катнаштылар, сугыш турында күп белүләрен күрсәттеләр.

21-25 нче апрель көннәрне мәктәптә **психологик атналык** итеп игълан ителгән иде. Без дә башлангыч сыйныф укучылары белән психологик тренинг үткәрдек. Укучыларга төрле биремнәр бирелде. Шул биремнәр ярдәмендә алар ничек дус-тату булырга, дөрес аралашырга, янәшәдәге иптәшеңне ничек бар шулай, бөтен кимчелекләре белән кабул итә белергә өйрәнделәр. "Толерантлык" төшенчәсе белән таныштылар. Бу тренинг нәтиҗәле булыр дип ышанабыз.

***Хәбәрләрне редколлгия әгъзаларытуплады***



**/Тәҗрибә уртаклашу/**

## "Үсеш ноктасы" мөмкинлекләре

16нчы апрель көнне күрше Емелькино мәктәбендә укытучыларыбыз Хәснуллин Фәнис һәм Туктамышев Рифкать абыйлар тарафыннан VII, VII һәм IX сыйныфлар өчен «Үсеш ноктасы үзәге мөмкинлекләре» темасына практик семинар үткәрелде. Бу чараның максаты белем бирүнең сыйфатын күтәрү өчен шартларны камилләштерүдән, укучыларның табигый юнәлештәге өстәмә белем бирү программаларын үзләштерү мөмкинлекләрен киңәйтүдән, шулай ук «Физика», «Химия», «Биология»уку предметлары буенча уку материалын практикада күрсәтү иде.

Укытучылар семинарда катнашучыларга мастер-класслар тәкъдим иттеләр, «Үсеш ноктасы» буенча тапшырылган җайланмаларда эшләп карадылар, төрле тәҗрибәләр уздырдылар. Семинар барышында химия, биология һәм физика буенча цифрлы лабораторияләрнең мөмкинлекләрен күрсәттеләр.

Биология укытучысы Туктамышев Рифкать абый укучылар белән «Цифрлы микроскоп белән танышу»дәресен үткәрде. Укучылар цифрлы микроскопның төзелешен өйрәнделәр. Микроскоп ярдәмендә алар барлык тереклекнең шулай нәзберек булуын яхшырак аңладылар. Шуңардан чыгып, үзләрен чолгап алган һәр нәрсәгә бик сак карарга кирәклеген аңладылар. Цифрлы микроскоп – гадәти дөнья белән микро дөнья арасындагы күпер дисәк тә була. Ул серле, гадәти булмаган һәм шуңа күрә гаҗәпләндерә. Ә барлык гаҗәеп нәрсәләр игътибарны нык җәлеп итә, баланың акылына тәэсир итә.

Дәрес барышында укучылар төрле экологик параметрларны үлчәүнең әһәмиятен аңладылар. Люксметр яктылык интенсивлыгын билгеләргә ярдәм итте, бу үсемлекләрнең фотосинтез процессы өчен мөһим. PH-метр суның кислоталылык дәрәҗәсен күрсәтте, бу организмнарның яшәү мохитенә тәэсир итә. TDS-метр суда эрегән минералларның күләмен билгеләп, суның сыйфатын бәяләргә мөмкинлек бирде.

Химия дәресендә укытучы бакыр, көмеш, кальций катионнарын, хлор, карбонат, сульфат анионнарын һәм хром тозларын билгеләүгә сыйфатлы химик реакцияләр күрсәтте. Төрле тирәлекләрдә индикаторларның эшен, һавадагы кислород күләмен билгеләделәр. Шулай ук углекислый газның ачык ут чыганагына тәэсире дә күрсәтелде.

Физика дәресендә укытучы Хәснуллин Фәнис абый үзенең хезмәттәшләренә һәм укучыларына «Үсеш ноктасы» үзәгенең физика буенча җиһазларын ничек кулланып булуын күрсәтте. Роботны демонстрацияләде. Укучыларга физиканың әһәмиятен, аның нинди фәннәр белән чиктәш булуын, физик күренешләрне кайда очратырга мөмкин булуы һәм физиканың безнең көндәлек тормышыбызда булуы турында сөйләде. Укучылар роботны кызыксынып өйрәнделәр, бик игътибар белән тыңладылар һәм төрле сораулар бирделәр.



Дәүләт йомгаклау аттестациясенә әзерлек тә читтә калмады. Укытучылар «үсеш ноктасы» җиһазлары ярдәмендә укучыларны биология, химия һәм физика буенча бердәм дәүләт имтиханына ничек әзерләргә икәнен күрсәттеләр.

Емелькино урта мәктәбе укучылары дәресләрдә, практик эшләрдә, мастер-класслар кысаларындагы тикшеренүләрдә бик теләп катнаштылар. Гомумән алганда, семинар уңышлы һәм файдалы булды.

***Фәнүзә Гафиятуллина, баш мөхәррир***